**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 16.02.2022** **№ 237**

## Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсен карау өчен гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32 статьяларына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына таянып, халыкның фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 9 мартка җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсен карау өчен гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә, атап әйткәндә – Емельянов Олег Николаевич милкендәге 1024 квадрат метр мәйданлы, 16:16:080202:135 кадастр номерлы һәм 741 квадрат метр мәйданлы, 16:16:080202:69 кадастр номерлы җир кишәрлекләрен «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» төреннән «кибет, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү» төренә, 14 сәгать 00 минутта, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау ав., Юбилей ур., 1А й., Биектау авыл җирлеге администрациясе бинасында.

2. Әлеге карарны һәм гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны Биектау авыл җирлеге территориясендәге махсус җиһазландырылган стендларда, Биектау авыл җирлеге территориясендә урнашкан ТР Биектау муниципаль районы карамагындагы биналарда 2022 елның 17 февраленнән 2022 елның 5 мартка кадәр чорда һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә (халыкка җиткерергә).

3. Гавами тыңлауларда каралырга тиешле мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне кабул итүне язма рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау станциясе т/юл.п., Кооператив ур., 5 йорт адресы буенча эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр 2022 елның 17 февраленнән 2022 елның 5 мартка кадәр чорда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдинов тарафыннан һәм

шулай ук 2022 елның 9 мартта турыдан-туры гавами тыңлаулар уздырганда гамәлгә ашырырга.

4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен һәм кисәтүләрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә. Тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерергә.

5. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә һәм аны Биектау авыл җирлеге территориясендәге, Биектау авыл җирлеге территориясендә ТР Биектау муниципаль районы карамагындагы биналарда махсус җиһазландырылган стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдиновка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов